ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01.12.2017 Казан ш. № 10-63/кс

Каты коммуналь калдыкларны күмүгә «Каты көнкүреш калдыклары полигоны» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2018-2020 елларга чик дәрәҗә тарифлар билгеләү хакында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәя хасил итү турында» 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карары, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2016 елның 21 ноябрендәге 1638/16 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Каты көнкүреш калдыклары полигоны» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә шушы карарның 1 нче кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән чик дәрәҗә тарифларны билгеләргә.

2. Шушы карарның 1 нче пунктында билгеләнгән тарифлар 2018 елның 1 гыйнварыннан башлап 2020 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. «Каты көнкүреш калдыклары полигоны» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә шушы карарның 2 нче кушымтасына туры китереп, 2018-2020 елларга чик дәрәҗә тарифларны җайга салуның дәвамлы параметрларын билгеләргә.

4. «Каты көнкүреш калдыклары полигоны» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә иркле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе

Хөкүмәтенең 2016 елның 21 июнендәге 564 номерлы карары белән расланган Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

5. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 01.12.2017 № 10-63/кс карарына 1 нче кушымта

Каты коммуналь калдыкларны күмү буенча «Каты көнкүреш калдыклары полигоны» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә 2018-2020 елларга календарь буенча бүленгән чик дәрәҗә тарифлар

| № п/п | Муниципаль берәмлекнең, каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик дәрәҗә тарифлар, сум/куб.метр | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2018 ел | | 2019 ел | | 2020 ел | |
| | | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән |
| | Азнакай муниципаль районы | | | | | | |
| 1 | «Каты көнкүреш калдыклары полигоны» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте* | 111,46 | 111,46 | 111,46 | 117,34 | 117,34 | 117,47 |

<*>Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 01.12.2017 № 10-63/кс карарына 2 нче кушымта

Каты коммуналь калдыкларны күмүгә «Каты көнкүреш калдыклары полигоны» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен 2018-2020 елларга чик дәрәҗә тарифларны җайга салуның дәвамлы параметрлары

| № п/п | Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре: электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | мең сум | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | «Каты көнкүреш калдыклары полигоны» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте | | | | | |
| 1.1 | Каты коммуналь калдыкларны күмү | 2018 | 8045,59 | 1 | - | 0,16 |
| | | 2019 | 8283,74 | 1 | - | 0,16 |
| | | 2020 | 8528,94 | 1 | - | 0,16 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге